**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕКАБАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

---

**2024елның «02» феврале** **1 номер**

## КАРАР

### Җир кишәрлеген файдаланунының шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясына ярашлы рәвештә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Мейзер Владимир Александрович гаризасы нигезендә, КАРАР ИТӘМ:

1. ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Үзәк урам, 42 ж/к адрес буенча урнашкан16:24:160201:3589 кадастр номеры белән 1000 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген " шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» төреннән «кибет» төренә шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2024 елның 16 февралендә 15.00 сәгатьтә ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Көньяк урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2024 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Лаеш районы Кече Кабан авылы, Көньяк урамы, 1 адресы буенча язма рәвештә җибәрергә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Олы Кабан**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Г. Шәрәфиев**